ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПОЛЯНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422643, д. Полянка,
ул. Механизаторов, дом 3б

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ПОЛЯНКА АВЫЛ ЖИРЛЕГЕНЕҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422643, Полянка авылы,
Механизаторлар урамы, 3б нче йорт

Тел.: (84361) 24002, Pol.Rs@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

18.03.2020 Полянка авыл № 3

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Полянка авыл җирлеге ”муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, 2003 елның 6 октябрендәге “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасының 2004 елның 24 мартындагы “Җирле референдум турында” 23-ТРЗ номерлы Законы,Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Полянка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, 2019 елның 16 ноябрендә узган гражданнар кабул ителгән 2 нче номерлы карарын тормышка ашыру максатында КАРАР БИРӘМ:

1.Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Полянка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыенның кушымта итеп бирелә торган Тәртибен расларга.

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянка авыл җирлегенең түбәндәге адреслар буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендларында: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Полянка авылы, Механизаторлар урамы, 3 б йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда урнаштырырга.

3.Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянска авыл җирлеге Башкарма комитетының баш бухгалтеры Харисова М.М.- гә йөкләргә.

Полянка авыл җирлеге Башлыгы
вазыйфаларын башкаручы
тоташу ноктасына кадәр уза.
ТР муниципаль районы Башлыгы Р. А. Сираев

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсемуниципаль
районы Полянка авыл
җирлеге Башкарма
комитетының 2019 елның
18 мартанда 3 нче номерлы
карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы**
**“Полянка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның**
**үзара салым акчаларын җыю**
**Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Полянка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю кагыйдәләрен билгели.

2. Гражданнарның үзара салым акчаларын түләү Татарстан Республикасы Балык Бистәсемуниципаль районы “Полянка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге территориясендә теркәлгән 18 яшькә җиткән гражданнар тарафыннан (белем алуның көндезге формасында укучы студентлардан гайре, аларның саны җирлектә яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан артык була алмый) җирле референдумда (гражданнар җыенында) катнашуларына һәм тавыш биргәндә алар тарафыннан белдерелгән мөнәсәбәтләргә бәй сезрәвештә 2020 елның 31 мартына кадәр башкарыла.

3. Бер тапкыр түләү турында хәбәрнамә бланкы (әлеге Тәртипкә кушымта) гражданнар игътибарына Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәгеhttp://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда игълан итүһәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштыру (халыкка белдерү) ысулы белән, шулай ук кул куйдырып тапшыру юлы белән яисә почта аша юллап җиткерелә.

Хәбәрнамәдә гражданнарның үзара салым акчасын күчерү реквизитлары, тулы яисә киметелгән күләмдә бер тапкыр түләнә торган түләү суммасы, аны түләү срогы булырга тиеш.

4. Гражданнарның үзара салымыннан алынган акча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Полянка авыл җирлеге” муниципаль берәмлегенең лицевой счетына керә.

5. Гражданнар тарафыннан түләүләр акча средстволарын физик затлар йөкләмәсе буенча исәп-хисап ясау хокукына ия булган, почта переводларын (исәп-хисап оешмалары) гамәлгә ашыру хокукына ия булган оешмалар аша, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Полянка авыл җирлеге Башкарма комитеты кассасы аркылы яки https://uslugi.tatarstan.ru/ сылтамасы буенчаТатарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша күчерү юлы белән башкарыла.

6. Түләү фактын раслаучы булып керем (приход) касса ордерының тамганамәсе, чек-ордер, түләү фактын раслаучы башка документлар тора.

7. Гражданнарның билгеләнгән срокта кертелмәгән үзара салым акчалары законнарда билгеләнгән тәртиптә түләттерелә.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
"Полянка авыл жирлеге"
муниципаль берәмлеге территориясендә
гражданнарның үзара салым акчаларын
жыю Тәртибенә КУШЫМТА

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсемуниципаль районы"_____________ авыл (шәһәр) җирлеге"
муниципальберәмлегебюджетынаүзара салым буенча
бер тапкыр түләнелә торган түләүне түләү турында
ХӘБӘРНАМӘ №_________

ТүләүченеңФ.И.А.и. ______________________________________________________
Адрес: ______________________________________________________
нигезендә Сезгә 2020 елның 31 мартына кадәр___________________________
_________________________________чараларын тормышка ашыруга бер тапкыр түләнелә торган ________сумма күләмендәге түләүне түбәндәге реквизитлар буенча түләргә кирәк: _____________________________________

БИК (банкның таныклаучы коды) алучы банк ___________________________
Сч. № __________________________________
Сч. № алучы_________________________________________
ИНН __________________________________________
КПП __________________________________________
КБК ________________ ОКАТО __________________
Түләүнең билгеләнеше
__________________________________________________________________________

Җитәкче _________________ _________________________________________
М.У. (имза) (имзаның расшифровкасы)

- - - - - - - - - - - - - - - - - **кисү сызыгы** - - - - - - - - - - - - - -

Татарстан Республикасы Балык Бистәсемуниципаль районы "_____________ авыл (шәһәр) җирлеге"муниципальберәмлегебюджетынаүзарасалымбуенчабертапкыртүләнеләторган _________________сум күләмендәгетүләүнетүләүтурындаХӘБӘРНАМӘ №_______________________
Түләүченең Ф.И.А.и. ______________________________________________
Адрес:_______________________________________________________________
Алдым "____"________________, 20__ ел _______________________________
(түләүченең имзасы)
*Искәрмә. Хәбәрнамә түләүчегә шәхсән тапшырылган очракта ертып алына торган төпсә тутырыла һәм ________________җирлеге Башкарма комитетында кала.*